Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Тураевская средняя общеобразовательная школа»
Менделеевского муниципального района Республики Татарстан

# Рабочая программа
# по родному языку (татарскому языку)
## ***для общеобразовательных организации с обучением на татарском языке***

Уровень образования: среднее общее образование, 10-11 классы

Разработано: ШМО учителей русского языка и литературы,
родного языка и литературы , иностранных языков

Татарстан Республикасы Менделеев муниципаль районы
Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе
“Турай урта гомуми белем бирү мәктәбе”

# *Татар телендә белем бирү оешмалары өчен*
# туган телдән (татар теленнән) эш программасы

Белем дәрәҗәсе(сыйныф): урта гомуми белем, 10-11 нче сыйныфлар

Эшләнгән: рус теле һәм әдәбияты, туган тел(тат.) һәм әдәбият(тат.), чит телләр укытучыларының ММБ

10-11 нче сыйныфта туган телдән (татар теленнән) эш программасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән программага “Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (10 – 11 нче сыйныфлар)”, төзүче-авторлары: Г.Р. Галиуллина, М.М. Шәкүрова, Казан, 2017, нигезләнеп төзелде.

**Дәреслекләр:**

| Сыйныф | Дәреслекләр авторы | Нәшрият |
|---|---|---|
| 10 | М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов | Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016 |
| 11 | М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов | Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2016 |

Барлыгы: **69** сәгатькә исәпләнгән (10 сыйныф- 35 сәгать, 11 сыйныф -34 сәг)

## Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә таләпләр

### 10 сыйныф.

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңларга;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре булу, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш булу;
- туган телдә аралаша алырга, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белергә;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белергә;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итү, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирү, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алыша белергә.
- сөйләмнең барлык төрләрен (тыңлау, аңлау, уку, язу) үзләштерергә: язма һәм сөйләм теленә караган мәгълүматның темасын, төп һәм өстәмә фикерен аңларга; төрле стильгә һәм жанрга караган текстларны дөрес укырга һәм аңларга; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белергә; сүзлекләрдән һәм электрон чаралардан дөрес файдалана белергә; аерым бер темага караган материалны тупларга, анализлый, эшкәртә һәм үзгәртә белергә;
- татар теленең төп функцияләрен, татар теленең башка төрки телләр арасында тоткан урынын, телнең мәдәният, җәмгыять белән тыгыз бәйләнешен аңларга;
- туган тел турындагы фәнни белемнәрнең нигезен булдырырга, тел катламнарының, ярусларының үзара бәйләнешен һәм мөнәсәбәтен аңларга;

- тел белеменең төп төшенчәләрен үзләштерергә, аның тармаклары турында мәгълүматлы булырга; тел һәм сөйләм, сөйләм төрләре, аралашу ситуацияләре; сөйләм теле, функциональ стильләр, матур әдәбият теле; текст һәм аның төрләре; телнең төп берәмлекләре, аларның аермалы билгеләрен, сөйләмдә кулланылу үзенчәлекләрен белергә;

- телнең төп стилистик чараларын, телнең әдәби нормаларын, сөйләм әдәбе нормаларын белергә, аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәнергә;

- тел һәм сөйләм берәмлекләрен аера һәм анализлый белергә; тел һәм стилистик чараларның кулланылышына бәйле рәвештә сөйләм төрләрен аера һәм чагыштыра белергә;

- телнең сәнгати чараларын, аларның эстетик функцияләрен белергә;

- татар теле, тарихы һәм мәдәниятенең башка халыклар мәдәнияте, теле һәм тарихы белән бәйләнешен белергә;

- татар теле үсешенең тарихын, үсеш этапларын һәм төп тенденцияләрне белергә;

- «сөйләм ситуацияләре һәм аның компонентлары», «әдәби тел», «тел нормалары», «сөйләм культурасы» төшенчәләренең мәгънәсен аңларга;

- телнең төп берәмлекләрен һәм дәрәҗәләрен, аларның билгеләрен һәм үзара бәйләнешләрен белергә;

- хәзерге татар әдәби теленең орфоэпик, лексик, грамматик, орфографик һәм пунктуацион кагыйдәләрен куллана алырга;

- сөйләм нормаларын иҗтимагый-мәдәни, уку-укыту, фән, рәсми аралашу даирәсендә куллану кагыйдәләрен белергә;

- үз сөйләмен контрольдә тотарга; тел кагыйдәләренең үтәлеше, куелган коммуникатив бурычларга ирешү эффектлылыгыннан чыгып телдән һәм язма сөйләмне бәяли белергә;

- тел берәмлекләрен дөреслек, төгәллек һәм урынлы куллану күзлегеннән анализлый белергә;

- төрле функциональ стильгә караган текстларга лингвистик анализ ясый белергә;

- коммуникация төренә карап, тиешле сөйләм этикеты кагыйдәләрен куллана белергә;

- фольклор, тарихи һәм әдәби әсәрләр мисалында милли-мәдәни компонентлы тел берәмлекләрен таный белергә;

- телдә чагылыш тапкан милли-мәдәни үзенчәлекләрне таный белергә, шул белемнәр нигезендә төрле тел күренешләрен аңлата белергә;

- укуда һәм көндәлек тормышта татар сөйләм культурасы кагыйдәләрен кулланырга;

*тыңлап аңлау һәм уку буенча:*

- коммуникатив бурычларга карап төп уку төрләрен кулланырга (танып белү максатыннан чыгып уку һ.б.);

- төрле чыганаклардан: дәреслекләр һәм фәнни текстлардан, белешмәләрдән, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, шул исәптән төрле электрон чыганаклардан кирәкле мәгълүматны сайлап алырга

*телдән һәм язма сөйләм буенча:*

- уку-укыту, фән, иҗтимагый-мәдәни һәм рәсми аралашу даирәләренә караган төрле типтагы һәм жанрдагы монологик һәм диалогик текстларны телдән һәм язмача төзергә;
- хәзерге татар әдәби теленең төп орфоэпик, лексик, грамматик кагыйдәләрен сөйләм практикасында кулланырга;
- хәзерге татар әдәби теленең төп орфографик һәм пунктуацион нормаларын язу практикасында сакларга;
- аралашуның төрле өлкәләрендә һәм очракларында, шул исәптән бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә, сөйләм нормаларын сакларга;
- телдән һәм язма текстларны мәгълүмати эшкәртүдә төп алымнарны кулланырга;
- этнокультур лексиканың мәгънәви кыйммәтен аңларга һәм сөйләмдә кулланырга.

**11 сыйныф**

- татар теленең татар халкы өчен төп милли-мәдәни кыйммәт булуын, ана телендә шәхеснең әхлакый, рухи һәм иҗади яктан формалашудагы ролен аңларга;
- туган телгә мәхәббәт һәм аның белән горурлану хисләре, туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк, омтылыш формалашкан булу;
- туган телдә аралаша алырга, үз фикереңне һәм хисләреңне төгәл, анык, күпьяклы итеп белдерү өчен кирәкле булган сүзлек составын һәм грамматик, стилистик чараларны белергә;
- аралашу төренә һәм ситуациясенә бәйле сөйләмне куллана һәм үзара бәйли белергә;
- иптәшләренең сөйләменә игътибар итеп, үзеңнең сөйләмеңә күзәтеп бәя бирергә, хаталарны төзәтү, бәхәстә катнашу, төрле дәлилләр кулланып, тема буенча фикер алыша белергә.

## Уку материалының эчтәлеге
## 10 сыйныф

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Сөйләм.** | Тел һәм сөйләм. Сөйләм формалары (телдән һәм язмача сөйләм; монологик һәм диалогик сөйләм). Телдән һәм язмача сөйләмнең төп үзенчәлекләре. Тыңлап аңлау вакытында монологик һәм диалогик сөйләмне аңлау культурасын камилләштерү. Төрле аралашу даирәсендә монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү | 3 |
| 2 | **Сөйләм эшчәнлеге төре буларак текст.** | Телдән һәм язма сөйләм. Текстның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. Текстта бәйләү чаралары. Текст структурасы. Текстларның композицион һәм жанр төрләре. | 3 |
| 3 | **Телнең** | Сөйләм теле, әдәби сөйләм теле, функциональ стильләр – фәнни, рәсми, электрон коммуникация | 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **функциональ төрләре.** | чаралары теле, аларның үзенчәлекләре. | |
| 4 | **5-9 сыйныфта үзләштерелгән материалларны кабатлау** | **5-9 сыйныфта үзләштерелгән материалларны кабатлау** | 3 |
| 5 | **Татар теле турында гомуми мәгълүмат** | Аралашу чарасы буларк тел. Рухи кыйммәтләр үрнәге буларак тел. Татар теленең язу тарихы. Рун, уйгыр, гарәп, латин һәм кирилл язулары турында төшенчә. Язма әдәби тел барлыкка килү. Хәзерге татар әдәби (милли) тел. Телнең кеше һәм җәмгыять тормышындагы роле. Әдәби тел төшенчәсе. Татар теленең яшәү формалары: гади сөйләм, территориаль һәм иҗтимагый диалектлар. | 4 |
| 6 | **Фонетика. Орфоэпия. Графика.** | Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә. Аваз. Фонема. Татар һәм рус телләрендә сузык авазлар системасы. Татар телендә басым. Интонация белән эшләү. Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Татар теленең орфографик принциплары. Татар теленең орфоэпик һәм орфографик кагыйдәләре. | 4 |
| 7 | **Лексикология һәм фразеология.** | Тел берәмлеге буларак сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Төрки-татар чыгышлы сүзләр һәм алынмалар. Татар теленең сүзлек запасы. Битараф һәм стилистик бизәкле сүзләр. Лексиканың стилистик катламнары. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрнең кулланылышы. Икетеллелек шартларында татар теленең фразеологик һәм лексик составын арттыру. Татар теленең төп лексик нормалары. Бәйләнешле сөйләм үстерү чаралары. Сүзгә лексик анализ ясау. | 4 |
| 8 | **Морфемика (телнең морфемик төзелеше) һәм сүз ясалышы.** | Сүз ясалышы һәм төзелеше турында гомуми мәгълүмат. Телнең иң кечкенә мәгънәле кисәге буларак морфема. Татар телендә сүз ясалыш ысуллары. Сүз структурасының тарихи үзгәреше турында гомуми мәгълүмат. Этимология төшенчәсе. Модаль кушымчалар. Морфемик һәм сүз ясалыш анализы | 3 |
| 9 | **Кабатлау.** | Контроль эш | 2 |
| 10 | **Тел һәм мәдәният.** | Татар халкының теле, мәдәнияте һәм тарихы арасындагы бәйләнеш. Татар халкының көнкүрешен билгели торган лексика; искергән сүзләр, фольклор лексикасы һәм фразеология; татар исемнәре. Татар мәкаль-әйтемнәре. Башка телләрдән алынган лексика, аларны үзләштерү үзенчәлекләре | 3 |
| 11 | **Татар халкының сөйләм этикеты.** | Коммуникация төренә карап, тиешле сөйләм этикеты кагыйдәләрен куллану | 2 |
| **Барлыгы** | | | 35 |

## 11 сыйныф

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгать саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Сөйләм.** | Сөйләм төрләре: рәсми һәм рәсми булмаган сөйләм, халык алдында һәм үзалдыңа сөйләү. Сөйләм ситуацияләре һәм аларның төп компонентлары. | 2 |
| 2 | **Сөйләм эшчәнлеге төре буларак текст.** | Текстка анализ ясау. Текст төзелеше кагыйдәләрен саклау (логикага буйсыну, бөтенлек, темага туры килү, эзлеклелек h.б.) | 2 |
| 3 | **Телнең функциональ төрләре.** | Сөйләм этикетының милли үзенчәлекләре, мәдәниятара коммуникациянең сөйләм кагыйдәләре. Халык алдында чыгыш ясау культурасын үзләштерү. Халык алдында чыгыш ясау: тема сайлау, максатны билгеләү, материал эзләү. Халык алдындагы чыгышның композициясе. Максат, адресат үзенчәлекләре, аралашу ситуациясе һәм даирәсенә карап, халык алдында чыгыш ясау өчен тел-сурәт чараларын сайлау.<br>Сөйләмнең әдәбилеге. Рәсми һәм рәсми булмаган аралашуда милли мәдәният кагыйдәләрен куллана белү.<br>Орфоэпик һәм интонацион кагыйдәләрне саклау; сөйләм этикеты формуласын урынлы куллану. Техник коммуникация чараларында сөйләм культурасын куллану (телефон, компьютер, электрон почта h. б.)<br>Әдәби әсәр теле һәм аның хәзерге татар теленең башка төрләреннән аермасы. Әдәби сөйләмнең төп үзлекләре: образлылык, тел-сурәтләү чараларының һәм шулай ук телнең башка функциональ төрләренә хас чараларның киң кулланылышы. | 6 |
| 4 | **Татар теле турында гомуми мәгълүмат.** | Дөнья телләре һәм аларның классификациясе. Тугандаш һәм тугандаш булмаган телләр. Төрки телләр гаиләсе. Төрки телләр гаиләсендә татар теленең урыны. Татарлар яши торган регионнар. Татар теле – татар әдәбияты теле. Татар телендә тел-сурәтләү чаралары һәм сөйләмдә аларның кулланылышы. | 2 |
| 5 | **Морфология.** | Лексик-грамматик разряд буларак сүз төркемнәре. Сүз төркемнәре классификациясе. Сүз төркемнәренең үзара бәйләнеше. Татар теленең төп морфологик нормалары. Бәйләнешле сөйләм үстерүнең морфологик чаралары. Сүзгә морфологик анализ ясау | 4 |
| 6 | **Синтаксис.** | Сүзтезмә һәм җөмлә. Җөмләдә синтаксик бәйләнеш. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Гади җөмлә төрләре. Кушма җөмләләр. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмлә төзелеше.<br>Текст синтаксисы турында гомуми мәгълүмат. Телнең төп синтаксик кагыйдәләре. Төп лексик тел-сурәтләү чаралары. Синтаксик анализ. | 4 |
| 7 | **Пунктуация**. | Татар теленең тыныш билгеләре. Пунктуацион-мәгънәви өзек. Татар теленең пунктуацион | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кагыйдәләре. | |
| 8 | **Стилистика һәм сөйләм культурасы.** | Сөйләмнең коммуникатив максатчанлыгы, урынлы булуы, төгәллеге, логикага буйсынуы, эзлеклелеге, образлылыгы, сөйләм сәнгатьлелеге турында төшенчә. Сөйләм культурасының төп аспектлары: норматив, коммуникатив һәм этик аспектлар. Хәзерге татар теленең сүзлекләре һәм белешмәләре: орфоэпик, аңлатмалы, орфографик сүзлекләр. Сөйләм практикасында әдәби сөйләм кагыйдәләрен саклау. Аралашу вакытында ситуациягә һәм даирәгә туры килә торган тел чараларын урынлы сайлау. Алга куелган коммуникатив бурычларга ирешү эффектлылыгыннан, урынлы һәм дөрес кулланылуыннан чыгып, телдән һәм язма текстларны бәяләү. Рәсми, фәнни һәм публицистик стильдәге текстлар төзегәндә орфографик, пунктуацион кагыйдәләрне үтәү. Телнең төрле функциональ төрләренә караган текстларга лингвистик анализ ясау. | 4 |
| 9 | **Кабатлау.** | **Контроль эш** | 2 |
| 10 | **Тел һәм мәдәният.** | Татар телендә татар халкының һәм башка халыкларның рухи һәм материаль кыйммәтләренең чагылышы. Милли мәдәниятләрнең үзара йогынты ясау нәтиҗәсе буларак тел байлыкларының үзара алмашуы. Татар теленең этноним һәм топонимнары турында төп мәгълүма | 3 |
| 11 | **Татар халкының сөйләм этикеты**. | Татар теленең сөйләм этикеты үзенчәлекләре. Текстка лингвистик анализ ясау, аңлатмалы, этимологик һәм фразеологик сүзлекләр ярдәмендә тексттан милли-мәдәни компонетлы берәмлекләрне табып алу | 2 |
| **Барысы** | | | 34 |

## Тематик планлаштыру
## 10 сыйныф

| № | Бүлекләр | Дәреснең темасы, эчтәлек элементлары |
|---|---|---|
| **1 чирек (9 сәг.)<br>Сөйләм (3 сәг.) Сөйләм эшчәнлеге төре буларак текст (3 сәг.)<br>Телнең функциональ төрләре (3 сәг.)** | | |
| 1 | **Сөйләм (3 сәг.)** | Тел һәм сөйләм. Сөйләм формалары (телдән һәм язмача сөйләм; монологик һәм диалогик сөйләм). |
| 2 | | Телдән һәм язмача сөйләмнең төп үзенчәлекләре. Тыңлап аңлау вакытында монологик һәм диалогик сөйләмне аңлау культурасын камилләштерү. |
| 3 | | Төрле аралашу даирәсендә монологик һәм диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү |
| 4 | **Сөйләм эшчәнлеге** | Телдән һәм язма сөйләм. Текстның мәгънәви һәм композицион бөтенлеге. |

| | | |
|---|---|---|
| 5 | **төре буларак текст (3 сәг.)** | Текстта бәйләү чаралары. Текст структурасы. |
| 6 | | Текстларның композицион һәм жанр төрләре. |
| 7 | **Телнең функциональ төрләре (3 сәг.)** | Сөйләм теле, әдәби сөйләм теле |
| 8 | | Функциональ стильләр – фәнни, рәсми стильләр. |
| 9 | | Электрон коммуникация чаралары теле, аларның үзенчәлекләре. |
| **2 чирек (7 сәгать)<br>Телнең функциональ төрләре (1 сәг.) 5-9 сыйныфта үзләштерелгән материалларны кабатлау (3 сәг.)<br>Татар теле турында гомуми мәгълүмат (3 сәг.)** | | |
| 10 | **Телнең функциональ төрләре (1 сәг.)** | Стиль үзенчәлекләре. |
| 11 | **5-9 сыйныфта үзләштерелгән материалларны кабатлау (3 сәг.)** | Кабатлау. Морфология һәм орфографияне кабатлау. |
| 12 | | Кабатлау. Синтаксис һәм пунктуацияне кабатлау. |
| 13 | | Кабатлау. Лексика һәм фразеологияне кабатлау. |
| 14 | **Татар теле турында гомуми мәгълүмат (3 сәг.)** | Аралашу чарасы буларак тел. Рухи кыйммәтләр үрнәге буларак тел. |
| 15 | | Татар теленең язу тарихы. Рун, уйгыр, гарәп, латин һәм кирилл язулары турында төшенчә. |
| 16 | | Язма әдәби тел барлыкка килү. Хәзерге татар әдәби (милли) тел. Телнең кеше һәм җәмгыять тормышындагы роле. |
| **3 чирек (10 сәг.)<br>Татар теле турында гомуми мәгълүмат (1 сәг.) Фонетика. Орфоэпия. Графика (4 сәг.) Лексикология һәм фразеология (4 сәг.)<br>Морфемика (телнең морфемик төзелеше) һәм сүз ясалышы (1 сәг.)** | | |
| 17 | **Татар теле турында гомуми мәгълүмат (1 сәг.)** | Әдәби тел төшенчәсе. Татар теленең яшәү формалары: гади сөйләм, территориаль һәм иҗтимагый диалектлар. |
| 18 | **Фонетика. Орфоэпия. Графика (4 сәг.)** | Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә. Аваз. Фонема.. |
| 19 | | Татар һәм рус телләрендә сузык авазлар системасы |
| 20 | | Татар телендә басым. Интонация белән эшләү. |
| 21 | | Графика һәм орфография турында гомуми мәгълүмат. Татар теленең орфографик принциплары. Татар теленең |

| | | |
|---|---|---|
| | | орфоэпик һәм орфографик кагыйдәләре. |
| 22 | **Лексикология һәм фразеология (4 сәг.)** | Тел берәмлеге буларак сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. |
| 23 | | Төрки-татар чыгышлы сүзләр һәм алынмалар. Татар теленең сүзлек запасы. Битараф һәм стилистик бизәкле сүзләр. |
| 24 | | Лексиканың стилистик катламнары. Сөйләмдә фразеологик әйтелмәләрнең кулланылышы. |
| 25 | | Икетеллелек шартларында татар теленең фразеологик һәм лексик составын арттыру. Татар теленең төп лексик нормалары. Бәйләнешле сөйләм үстерү чаралары. Сүзгә лексик анализ ясау. |
| 26 | **Морфемика (телнең морфемик төзелеше) һәм сүз ясалышы (1 сәг.)** | Сүз ясалышы һәм төзелеше турында гомуми мәгълүмат. Телнең иң кечкенә мәгънәле кисәге буларак морфема |
| **4 чирек (8 сәг.)<br>Морфемика (телнең морфемик төзелеше) һәм сүз ясалышы (2 сәг.) Кабатлау. Контроль эш (2 сәг.)<br>Тел һәм мәдәният (3 сәг.) Татар халкының сөйләм этикеты (2 сәг.)** | | |
| 27 | **Морфемика (телнең морфемик төзелеше) һәм сүз ясалышы (2 сәг.)** | Татар телендә сүз ясалыш ысуллары |
| 28 | | Сүз структурасының тарихи үзгәреше турында гомуми мәгълүмат. Этимология төшенчәсе. Модаль кушымчалар. Морфемик һәм сүз ясалыш анализы |
| 29 | **Кабатлау. Контроль эш (2 сәг.)** | Кабатлау |
| 30 | | Контроль диктант |
| 31 | **Тел һәм мәдәният (3 сәг.)** | Татар халкының теле, мәдәнияте һәм тарихы арасындагы бәйләнеш |
| 32 | | Татар халкының көнкүрешен билгели торган лексика; искергән сүзләр, фольклор лексикасы һәм фразеология; татар исемнәре |
| 33 | | Татар мәкаль-әйтемнәре. Башка телләрдән алынган лексика, аларны үзләштерү үзенчәлекләре |
| 34 | **Татар халкының сөйләм этикеты (2 сәг.)** | Коммуникация төренә карап, тиешле сөйләм этикеты кагыйдәләрен куллану. |
| 35 | | Татар телендә сөйләм этикеты кагыйдәләрен куллану |

## 11 сыйныф

| № | Бүлекләр | Дәреснең темасы, эчтәлек элементлары |
|---|---|---|
| **1 чирек (9 сәг.)**<br>**Сөйләм (2 сәг.) Сөйләм эшчәнлеге төре буларак текст. (2 сәг.) Телнең функциональ төрләре. (5 сәг.)** | | |
| 1 | **Сөйләм (2 сәг.)** | Сөйләм төрләре: рәсми һәм рәсми булмаган сөйләм, халык алдында һәм үзалдыңа сөйләү |
| 2 | | Сөйләм ситуацияләре һәм аларның төп компонентлары |
| 3 | **Сөйләм эшчәнлеге төре буларак текст (2 сәг.)** | Текстка анализ ясау |
| 4 | | Текст төзелеше кагыйдәләрен саклау (логикага буйсыну, бөтенлек, темага туры килү, эзлеклелек һ.б.) |
| 5 | **Телнең функциональ төрләре (5 сәг.)** | Сөйләм этикетының милли үзенчәлекләре, мәдәниятара коммуникациянең сөйләм кагыйдәләре |
| 6 | | Халык алдында чыгыш ясау культурасын үзләштерү. Халык алдында чыгыш ясау: тема сайлау, максатны билгеләү, материал эзләү |
| 7 | | Халык алдындагы чыгышның композициясе. Максат, адресат үзенчәлекләре, аралашу ситуациясе һәм даирәсенә карап, халык алдында чыгыш ясау өчен тел-сурәт чараларын сайлау |
| 8 | | Сөйләмнең әдәбилеге. Рәсми һәм рәсми булмаган аралашуда милли мәдәният кагыйдәләрен куллана белү |
| 9 | | Орфоэпик һәм интонацион кагыйдәләрне саклау; сөйләм этикеты формуласын урынлы куллану. Техник коммуникация чараларында сөйләм культурасын куллану (телефон, компьютер, электрон почта һ. б.) |
| **2 чирек (7 сәг.)**<br>**Телнең функциональ төрләре. (1 сәг.) Татар теле турында гомуми мәгълүмат (2 сәг.)**<br>**Морфология (4 сәг.)** | | |
| 10 | **Телнең функциональ төрләре. (1 сәг.)** | Әдәби әсәр теле һәм аның хәзерге татар теленең башка төрләреннән аермасы. Әдәби сөйләмнең төп үзлекләре: образлылык, тел-сурәтләү чараларының һәм шулай ук телнең башка функциональ төрләренә хас чараларның киң кулланылышы |
| 11 | **Татар теле турында гомуми мәгълүмат (2 сәг.)** | Татар теле турында гомуми мәгълүмат**.** Дөнья телләре һәм аларның классификациясе. Тугандаш һәм тугандаш булмаган телләр. Төрки телләр гаиләсе. Төрки телләр гаиләсендә татар теленең урыны. Татарлар яши торган регионнар |
| 12 | | Татар теле – татар әдәбияты теле. Татар телендә тел-сурәтләү чаралары һәм сөйләмдә аларның кулланылышы |
| 13 | **Морфология (4** | Морфология. Лексик-грамматик разряд буларак сүз төркемнәре. Сүз төркемнәре классификациясе |

| | | |
|---|---|---|
| 14 | **сәг.)** | Сүз төркемнәренең үзара бәйләнеше. Татар теленең төп морфологик нормалары |
| 15 | | Бәйләнешле сөйләм үстерүнең морфологик чаралары |
| 16 | | Сүзгә морфологик анализ ясау |
| **3 чирек (10 сәг.) Синтаксис (4 сәг.) Пунктуация (3сәг.) Стилистика һәм сөйләм культурасы (3 сәг.)** | | |
| 17 | **Синтаксис (4 сәг.)** | Синтаксис. Сүзтезмә һәм җөмлә |
| 18 | | Җөмләдә синтаксик бәйләнеш. Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Гади җөмлә төрләре |
| 19 | | Кушма җөмләләр. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмлә төзелеше |
| 20 | | Текст синтаксисы турында гомуми мәгълүмат. Телнең төп синтаксик кагыйдәләре. Төп лексик тел-сурәтләү чаралары. Синтаксик анализ |
| 21 | **Пунктуация (3сәг.)** | Пунктуация. Татар теленең тыныш билгеләре |
| 22 | | Пунктуацион-мәгънәви өзек |
| 23 | | Татар теленең пунктуацион кагыйдәләре |
| 24 | **Стилистика һәм сөйләм культурасы (3 сәг.)** | Стилистика һәм сөйләм культурасы. Сөйләмнең коммуникатив максатчанлыгы, урынлы булуы, төгәллеге, логикага буйсынуы, эзлеклелеге, образлылыгы, сөйләм сәнгатьлелеге турында төшенчә. Сөйләм культурасының төп аспектлары: норматив, коммуникатив һәм этик аспектлар |
| 25 | | Хәзерге татар теленең сүзлекләре һәм белешмәләре: орфоэпик, аңлатмалы, орфографик сүзлекләр. Сөйләм практикасында әдәби сөйләм кагыйдәләрен саклау. Аралашу вакытында ситуациягә һәм даирәгә туры килә торган тел чараларын урынлы сайлау |
| 26 | | Алга куелган коммуникатив бурычларга ирешү эффектлылыгыннан, урынлы һәм дөрес кулланылуыннан чыгып, телдән һәм язма текстларны бәяләү. Рәсми, фәнни һәм публицистик стильдәге текстлар төзегәндә орфографик, пунктуацион кагыйдәләрне үтәү. |
| **4 чирек (8 сәг.) Стилистика һәм сөйләм культурасы (1 сәг.) Кабатлау. Контроль эш (2 сәг.) Тел һәм мәдәният (3 сәг.) Татар халкының сөйләм этикеты (2сәг.)** | | |
| 27 | **Стилистика һәм сөйләм культурасы (1 сәг.)** | Телнең төрле функциональ төрләренә караган текстларга лингвистик анализ ясау |
| 28 | **Кабатлау. Контроль эш (2 сәг.)** | Кабатлау. Сөйләм. Сөйләм эшчәнлеге төре буларак текст. Телнең функциональ төрләре. Татар теле турында гомуми мәгълүмат. Морфология. Синтаксис. Пунктуация. Стилистика һәм сөйләм культурасы. Стилистика һәм сөйләм культурасы. |
| 29 | | Контроль эш |

| | | |
|---|---|---|
| 30 | **Тел һәм мәдәният (3 сәг.)** | Тел һәм мәдәният. Татар телендә татар халкының һәм башка халыкларның рухи һәм материаль кыйммәтләренең чагылышы. |
| 31 | | Милли мәдәниятләрнең үзара йогынты ясау нәтиҗәсе буларак тел байлыкларының үзара алмашуы. |
| 32 | | Татар теленең этноним һәм топонимнары турында төп мәгълүмат |
| 33 | **Татар халкының сөйләм этикеты (2сәг.)** | Татар халкының сөйләм этикеты. Татар теленең сөйләм этикеты үзенчәлекләре. |
| 34 | | Текстка лингвистик анализ ясау, аңлатмалы, этимологик һәм фразеологик сүзлекләр ярдәмендә тексттан милли-мәдәни компонетлы берәмлекләрне табып алу |